**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Иске Үтәмеш авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлегенең**
**гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге составына керүче Иске Сережкино торак пунктында

**14 октябрь 2025 ел** **№6**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлегенең Иске Сережкино торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2026 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлегенең Иске Сережкино торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш

-торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту) Иске Сережкино торак пунктында ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу; Иске Сережкино торак пунктында ике дәүләт телендә (рус һәм татар телләрендә) бертөрле төстәге һәм ясалыштагы урамнарның табличкаларын (күрсәткечләрен) һәм йортларның номерларын әзерләү;

- Иске Сережкино торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

-Иске Сережкино торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җайланмаларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен бүтән билгеләнештәге урыннарны ремонтлау (Иске Сережкино торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

-җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү, Иске Сережкино торак пунктындагы чишмәләрне ремонтлау һәм аларга хезмәт

күрсәтү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

-Иске Сережкино торак пунктында су чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

-Иске Сережкино торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү.

2. Әлеге карарны Иске Сережкино авылы, Степная урамы, 7а йорт адресы буенча мәгълүмати стендларда һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлегенең Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Иске Үтәмеш авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.С.Мингулов